Бүгенге санда:



**Депутатка сукмак өзелми.**
**Быелның беренче кабул итүенә 19 кеше килгән.** 2 бит.


# Дуслык
Дружба

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

1931 елның 9 июленнән бирле чыга

Чәршәмбе
28
гыйнвар
2015 ел
№ 5 (10534)


**29 гыйнварга һава торышы:** болытлы һава; урыны белән кар; җил көньяктан, 3-4 м/с; температура көндез -17°С, төнлә -17°С

*Абзац-информ*

ХӘБӘРЛӘРЕГЕЗНЕ КӨТӘБЕЗ

Телефоннар: 2-36-13, 2-36-20.

### РЕСПУБЛИКАДА – ИКЕНЧЕ

2нче урта мәктәп укучысы Диләрә Әбҗәппарова инглиз теле буенча республика олимпиадасында уңышка ирешеп кайтты. Максималь 120 баллдан 102не туплап, кыз II урынга чыккан. Шул рәвешле, Диләрәнең уңышы җитәкчесе Татьяна Куколеваның 55 яшьлек юбилеена да зур бүләк булган.

### ҖЫЕННАР АКТИВ УЗА

Бүгенге көнгә районның 12 авылында гражданнар җыеннары узды. Якшәмбе көнне Мамык, Тәрнәс, Егоркино, Әхмәт һәм Якушкино авыл җирлекләрендә халык белән очрашулар үтте. Бу хакта тулырак nurlat.tatarstan.ru сайтыннан укый аласыз.

### МАШИНАЛЫ БУЛДЫЛАР

Районның мәдәният бүлегенә "Lada Largus" автомобиле бирелде. Мәдәният хезмәткәрләренә әлеге бүләкне республика һәм федераль үзәкләр ясаган. Кичә район мәдәниятчеләре Казанда тармакның коллегия утырышында катнаштылар.

### ӨЛКӘННӘР КОМПЬЮТЕРДА ЯРЫША

Кичә Казанда пенсионерлар арасында узган "Интернет – озын гомерлелек" республика олимпиадасында бездән муниципаль турда җиңү яулаган Роза Абдуллина һәм Рәйсә Фәйзуллина катнаштылар. Олимпиадада исә республикадан 2013/14 уку елында компьютер грамоталылыгы нигезләрен үзләштергән 109 пенсионер үз белемен күрсәткән.

### ХЕЗМӘТ ХАКЫГЫЗ "АКМЫ"?

Район башкарма комитетының территориаль үсеш бүлегенә ел башыннан бюджеттан тыш өлкәдә эш бирүчеләрдән 120 хезмәт килешүе кергән. **"Соры" хезмәт хакы, рәсми булмаган мөгълүлек турындагы хәбәрләрне җиткерү өчен "кайнар линия" тел.: 2-06-69.**

# Чаңгычыларны суык куркытмый




**Көннәрнең шактый суык булуына да карамастан, шикәрчеләр бистәсендә яшәүчеләр стадионга рәхәтләнеп чаңгы шуарга йөриләр.**

Күпләр телевизор аша биатлончыларыбыз өчен җан аткан бер вакытта, алар үз рекордларын куя торалар. Көндезләрен бергә лаеклы ялда булганнар килә. Алар сәламәтлек өчен йөриләр. Һәм бу кешеләрнең оптимистлыгы һәм энергияләре һәркемне көнләштерерлек. "Ашыкмый гына берничә әйләнеш ясыйм – көн буена миңа дигән зарядка. Кеч тә арта, сулыш алу да яхшыра. Яшь чакта чаңгыда йөрергә ярата идем, аннан ташладым, ә узган ел кышын янә чаңгыга бастым. Хәзер миңа күпме вакытымны югалтканмын икән дип күрсәнәм. Мөгаен, нәкъ әнә шул әрәмгә узган көннәр өчен дә бүген стадионга һәр көнне килергә тырышам", – ди Любовь Долганова.

Символик эстафетаны дәресләрдән соң укучылар дәвам итә, ә инде кичен чаңгы юлларына аларның ата-аналары баса. Һәм барысы да бер-берләрен беләләр, чөнки стадионга беренче ел гына йөрүләре түгел бит.

Галина Рожкованың мәктәп елларыннан бирле чаңгыдан аерылганы юк. Дусты Венера Черноиванова белән кичләрен стадионга чаңгыда йөрергә еш киләләр алар. Надежда Овчинникова да эш көненнән соң кеч тупларга биргә ашыга. "Табиб булара, барыгызга да сәламәт яшәү рәвеше алып барырга киңәш итәм, авырмассыз, хастаханәгә дә сирәк йөрерсез", – ди ул һәммәсен спорт белән шөгыльләнергә өндәп. Һәм бу кыш чорына гына кагылмый. Чөнки җәен дә стадион футбол уеннары белән генә чикләнми, күпләр биргә велосипедта йөрергә, йөгерергә киләләр.

"Тренажерлар куеп, территориясен дә тәртипкә китерсәң, бигрәк тә шәп булыр иде. Бу стадионда берничә буын үсте бит. Әле тагын күпме булачак алар?" – чаңгычыларның бу фикерен шикәрчеләр бистәсендә яшәүчеләрнең күбесе хуплыйдыр, мөгаен. Чөнки сәламәт яшәү рәвеше әлегәчә модада бит.

**Маргарита ЛИТТА**

ТЕЛДӘН-ТЕЛГӘ

# Кайда син, физиологик эремә?

**Район хастаханәсендә генә түгел, шәһәр даруханәләрендә дә физэремә дефицит препаратларның берсенә әверелде.**

Бу проблеманың сәбәбе нидә соң? Кайбер даруханәләрдә препарат фирмаларда юк, диләр, башкалары үзләрендә физиологик эремә кайчан булганын бөтенләй дә онытканнар инде. Үзәк даруханәгә физэремә даими кайтып тора, әмма аны "чират буенча" тиз арада алып бетерәләр: кешеләр чарасызлыктан алдан язылып куялар һәм фармацевтлар препаратның кайтуы турында телефоннан хәбәр итәләр икән.

– Бу проблема берничә ай элек пәйда булды, – диде 94нче район үзәк даруханәсе мөдире Илдар Зәкуанов. – Республиканың башка районнарында да шул ук хәл, бу россиякүләм проблема хәзер. Әмма без поставщиклар әзлибез, заказлар бирәбез.

Кичә көннең беренче яртысында үзәк даруханәдә 400 миллилитрлы зур шешәдәге физэремә алырга була иде ле, тик аның көн азагына яки икенче көнгә кадәр булачагына гарантия юк. Физэремә билгеләнгән авыруларның туганнары, хастаханәдә бу препарат булмаганлыктан, даруханә бусагаларын таптый башлыйлар. Нурлат районы хастаханәсенең баш табибы Марат Йосыпов та препаратның ни өчен дефицитка әверелүен әлегә аңлата алмый.

– Кичә Казанда да бу хәл турында фикер алышынды, башка хастаханәләрдә дә шул ук проблема, – диде ул. – Хәзер без физэремәә аналогларына заказлар бирәбез, алар кайта башлады инде. Әмма проблема калачак, чөнки бу препаратлар кыйммәтрәк.

Даруханәләрдә физэремәнең юкка чыгуы турында Интернет челтәрендә узган атнада фикер алышу башланган иде. Һәм барлык форумнарда бер үк сорау: физэремә кая юкка чыкты? Шунда ук физэремәгә охшаш препаратларны кайдан алып булуы турындагы электрон адреслар да күренгәли. Тик аларның бәяләре шактый аерыла. Әмма безнең халык төрле дефицитларга күнгән. Инде физэремәне өй шартларында ясый башлаучылар да бар, әмма ул ингаляция өчен генә яраклы. Ә препаратны кан тамыры аша кертү билгеләнгәннәргә ныграк әзләнергә туры килер, мөгаен: әлегә физэремә сәбәбен әйтми генә дефицитта кала бирә.

**Сирень СӘМӘРХАНОВА**

ӘБУНӘ-2015



## Вакытыннан алда язылу башлана

**1 февральдән "Татарстан почтасы" "Дуслык" газетасына 2015нче елның икенче яртыеллыгына беренче яртыеллык бәяләреннән вакытыннан алда әбунә ачып җибәрә. Форсаттан файдаланыгыз!**

# РАЙОН ТОРМЫШЫ

ОЧРАШУЛАР

## Халык вәгъдәләләрне ярата

– Ел ярым эчендә район башлыгы өченче тапкыр очрашуга килде, үтенечләребез сүздә генә калмый, үтәлә дә тора. Рәхмәт әйтми ни дисең инде?

Шуңа охшаш сүзләрне 22 гыйнварда Әлмәт кустындагы халык җыеннары үткән барлык авылларда да диярлек ишетергә туры килде. Сүзләр нигезле иде: чыннан да, һәр биш авылда да халыктан кергән үтенечләрнең иң тәҗелләреннән берничәсе булса да үтәлгән, агымдагы елга билгеләнгәннәре дә байтак. Әнә, Колбай Мораса урамнарына узган ел 70 энергия саклагычлы яктырткыч куелган, быел авыл эченә юл сузу мәсьәләсе хәл ителгән, мәктәп капиталь ремонт программасына кертелгән. Чурабатыр, Яңа Әмзәдә яктырту мәсьәләсе уңай хәл ителгән, ниһаять, авыл хуҗалыгы җирләре яңа инвесторга тапшырылган. Быел Яңа Әмзәдә су үткәрү, Чурабатырга кадәр юл түшәү эшләре башкарылачак. Иске Әлмәт авыл җирлегендә су линиясе сузылган, бу эш быел да дәвам итәргә тора. Халык үтенече буенча, атнага ике тапкыр районнан стоматолог килү буоештырылган, аптека пункты ачу буенча эш бара. Район башлыгының бу авылларда агрофирма оештыру, шул рәвешле халыкка эш урыннары булдыру турындагы хәбәрен дә халык шатланып кабул итте. Кычытканлыда да авыл урамнарын яктырту буенча проблема юк, буалар төзекләндерелгән. Сәләнгештә авыл эчендә утлар кую быелгы планга кертелгән, балалар бакчасы ачу турындагы сорауны да район башлыгы мөмкинлекне өйрәнеп, ТР Мәгариф Министрлыгына чыгарга вәгъдә бирде. Әлбәттә, сораулар кирә дә торды, алар беркетмәгә теркәлеп, аерым службалар җаваплылыгына тапшырылачак. Байтагы шунда ук җиткерелде дә, чөнки очрашуда районның барлык служба җитәкчеләре дә катнаша бит. Сөйләшү вакытында яңгыраган әлеге авылларга рейс автобусын йөртү үтенечен район башлыгы шунда ук АТП җитәкчелегенә хәл итәргә йөкләде. Авылларда идән астыннан аракы сатучыларга карата МВД бүлегенә иң кырыс чараларны күрергә кушты. Авыл халкыннан сөтне сатып алу бәяләре турында кергән сорау уңаеннан, Равил Әфраимович икенче көнне үк сөт җыючыларны чакыртып, сөйләшү үткәрде. Җыеннарда мәктәп автобуслары салкынлыгына, хезмәт хакы түләүгә кагылышлы сораулар да игътибарсыз калмады. Авыл җирлекләре башлыклары исә җирлек проблемаларын хәл итүдә самообложение әйбәт чыганак булачак дип, аерым искәртеп үттеләр, бу уңайдан референдумда актив катнашырга чакырдылар.

Очрашу алдыннан һәр авыл җирлегендә үзешчәннәр иҗади хисап тоттылар.

– Ел икътисадый яктан катлаулы булса да барлык социаль программалар эшләячәк, – дип ассызыклады һәр авылда район башлыгы һәм планнарны гамәлгә ашыруда бергә, бердәм эшләргә чакырды.

**Сәкинә ХӘЙРУЛЛИНА**



СӘЛӘНГЕШТӘ ҖЫЕН АЛДЫННАН АВЫЛ ҮЗЕШЧӘННӘРЕ КОНЦЕРТЫН ЯРАТЫП КАРАДЫЛАР

Автор фотосы

### ТӘКЪДИМНӘР:

*"Республикадагы төрле дәрәҗә советларга сайланган депутатлар белән очрашулар уздырылсын иде!*

**Әнвәр Фәссахов, Яңа Әмзә."**

*"Авылның атаклы кешеләре турында материаллар туплап, аерым китап чыгарасы иде.*

**Сөләйман Мотаһиров, Кычытканлы."**

*"Әйдәгез, балалар мәйданчыгын бергәләп төзик!*

**Екатерина Пинина, Сәләнгеш."**

*"Авыл мәдәният йортларын музыкаль инструментлар белән тәэмин итүне яхшыртасы иде.*

**Таһирә Мингәрәева, Колбай Мораса."**

ДЕПУТАТ ХОЗУРЫНДА

## Проблемалар күп төрле

**Татарстан Дәүләт Советы депутаты Илгиз Салиховның чираттагы кабул итүенә язылучылар арасында сугыш ветераннары һәм аларның толлары да бар иде.**

Сугыш михнәтләрен башларыннан кичергән сайлаучыларын тыңлаганнан соң, Илгиз Мисбахович Җиңүнең 70 еллыгы елында әлеге кешеләрнең ныклы игътибарда булырга тиешлеген ассызыклады. Мисал өчен, сугыш ветераны толы, тыл хезмәтчәне Зоя Куликова фатирын ремонтлауга мохтаҗ. Кайчандыр ул район җитәкчелегенә мөрәҗәгать иткән дә булган, әмма программа буенча ветераннарга торак бирелә, ә менә аны ремонтлау каралмаган, дигәннәр. Депутат тиз арада Зоя Никитичнаның ире эшләгән предприятие җитәкчелеге белән элемтәгә керде.

– Үземне тыңлаганнары һәм аңлаганнарыннан мин бик канәгать, – диде сайлаучы кабул итүдән киткәндә.

Мария Максимова узган кабул итүдә булган иде, бу юлы ярдәм иткәннәре өчен рәхмәт әйтергә килгән. Ул чагында Илгиз Салихов булышкан: өенең түбәсен алыштырганнар.

Хәл итәрбез. Бу кыска, әмма депутат ярдәменә мохтаҗлар өчен бик тә тирән мәгънәле һәм мөһим сүзләр. Авыру балалары булган яшь гаилә дә әнә шундый җавап алды. Сабыйның авыруы җитди, зур матди чыгымнар таләп ителә. Әмма, әти-әни әйтүенчә, мондый дәва файдалы икән – алга китеш бар, ди. Хәзер балага инвалидлык ясап йөриләр, әмма билгеләнгән дару препаратлары бушлай бирелүчеләр исемлегенә кермиләр икән. Илгиз Салихов республиканың Сәламәтлек саклау министрлыгына һичьюгы чыгымнарның бер өлешен булса да каплау мөмкинлеген сорап мөрәҗәгать итәчәкмен, диде.

Балалары авыруыннан нишләргә белмәгән ата-аналарның депутатка килүенең бердәнбер очрагы гына түгел бу. Нурлаттан бер ханым улы авырганлыктан эшен ташлаган. 32 ел хезмәт стажы була торып та, аңа 5800 сум пенсия билгеләгәннәр.

– Мөмкинлек булса, ярдәм итәрбез, – диде депутат.

Берничә сайлаучы торак проблемалары белән килгәннәр. Мәсәлән, авария хәлендәге дип танылган йортта яшәүчеләргә Илгиз Салихов фатир алу механизмын аңлатты. Пропискага керә алмаучыларны да тыңлады. Эш шунда, 90нчы елларда торак булмаган, әмма фатир итеп әмәлләнгән бинада яшәгән әлеге кешеләр бүгенгә кадәр үзләре торган почмакта пропискага керә алмыйлар. Аларга я проект ясарга, яисә түбәләрен ремонтлауны тәкъдим итеп торганнар, әмма бинаны торак булмаган фондтан торакка һич тә күчермиләр икән. Ә бит әлеге кешеләр коммуналь хезмәтләр өчен төгәл түләп бара. Илгиз Мисбахович бу мәсьәлә буенча район җитәкчелегенә ходатайство белән чыгарга вәгъдә бирде.

Депутатка бу юлы да эшкә урнашу мәсьәләсе буенча килүчеләр булды. Сугым цехы, билбау көрәше кебек мәсьәләләр буенча борчылып килүчеләр дә бар иде. Илгиз Салихов, җавап бирер алдыннан, һәр мәсьәләне җентекләп өйрәнде. Чөнки, аның үзе әйткәндәй, барысы да депутат кодрәтендә түгел бит, әмма иң мөһиме – сайлаучыларның хокуклары кысылмасын.

**Сирень СӘМӘРХАНОВА**

САН

**19**

**– быелгы беренче кабул итүдә депутатка әнә шулкадәр сайлаучы килде.**

ХӘБӘРЛӘР

### ПАРЛАМЕНТ ЯШЬЛӘРНЕ ХУПЛЫЙ

**Нурлат районында 1 мартка кадәр Яшьләр парламенты барлыкка килергә тиеш. Моңа ТР Президентының "ТР муниципаль берәмлекләре, закон чыгару органнары каршында иҗтимагый яшьләр парламентларын формалаштыру турында"гы Йөкләмәсе нигез булып тора.**

Яшьләр парламенты яшьләрнең хокуклары, законлы мәнфәгатьләре темалары буенча район һәм шәһәр Советлары комиссияләре эшчәнлегендә катнашачак, хокукый культураны арттыру һәм актив гражданлык позициясен формалаштыруга юнәлтелгән аңлату эшләре үткәрәчәк. Парламентка кандидатлар 30 яшьләре тулмаган, республика яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләренең район вәкиллекләре әгъзалары, укучыларның "Политзавод" проекты муниципаль этабы җиңүчеләре арасыннан сайланачак. Җирле яшьләр парламентын ТР Дәүсоветы каршындагы Яшьләр иҗтимагый палатасы әгъзасы Ленар Әһлиуллин җитәкләячәк.

**Гөлназ ГАЗИЗОВА**

### КАР МАШИНАЛАРЫН ТИКШЕРӘЛӘР

**19 гыйнвардан 20 февральгә кадәр Татарстанның Гостехнадзор идарәсе "Снегоход" операциясе игълан итте.**

- Гостехнадзорның Нурлат районы буенча бүлеге тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр еш кына мондый төр моточараларны эксплуатацияләү кагыйдәләренең үтәлмәвен күрсәтә. Хуҗалары моточараларны вакытында теркәмиләр, техника карау үткәрмиләр, я булмаса тиешле документлары юк, - ди бүлек начальнигы вазифаларын башкаручы Газинур Зәйдуллин. – Айлык барышында әлеге категория машиналарның төзеклегенә, комплектлануына, дәүләти теркәү кагыйдәләренең үтәлешенә һәм башкаларга зур игътибар биреләчәк. Ә кагыйдә бозучылар РФ КоАПы нигезендә административ җаваплылыкка тартылачак.

Гостехнадзор идарәсе белгечләре берүк вакытта барлык төр транспорт чараларын дәүләти теркәү кагыйдәләрен бозган өчен штраф күләме артуын да искәртә. Ул гражданнарга 1500-2000, вазифаи затларга 2000–3500, юридик затларга 5000–10000 сум тәшкил итә.

**Лилия МӨБАРӘКШИНА**

### НУРЛАТТА "ҮЛЕМСЕЗ ПОЛК" САФЛАРЫ КИҢӘЯ

"Легенда" хәрби-патриотик клубының актив әгъзалары Алексей Халипа белән Владимир Малыгинның шәһәрдә "Үлемсез полк" акциясе үткәрү инициативасы күп нурлатлыларда кызыксыну уятты. Полкка үзләренең фронтовик туганнарын яздырырга теләүчеләрнең саны арта бара. Редакциягә кергән күпсанлы шалтыратулар да шул хакта сөйли. Укучыларыбызның сораулары буенча, Нурлатта "Үлемсез полк" оештыручыларның телефоннарын хәбәр итәбез.

**Владимир Малыгин– 8-927-439-69-45;**
**Алексей Халипа – 8-927-422-77-96.**

**Маргарита ЛИТТА**

### РЕЙДЛАР УЗАЧАК

19 гыйнвардан 30ына кадәр 73нче янгын часте сагындагы объектларда "Нурлатнефть" НГДУсы, "Татнефтеотдача" ААҖнең 2нче ЦДНГсы янгын-техник комиссияләре, шулай ук кызыксынган службалары белән берлектә беренчел янгын сүндерү чараларын тикшерү буенча рейдлар үткәрелә.

**Галина ПИЯНЗИНА,**
73нче янгын часте инспекторы

НЕФТЬЧЕЛӘР ТОРМЫШЫ

# Нурлатта "Татнефть" Спартакиадасы ачылды

**Өстәл теннисының кайчан һәм кайда барлыкка килгәнлеге турында әлегә кадәр бәхәсләр йөри. Әмма аның иң җитез спорт төре икәнлеге һәркемгә билгеледер, мөгаен. Өстәл теннисы уйнар өчен бик җитез булырга кирәк. Узган шимбәдә нефтьчеләр "Татнефть" ААҖнең XXVIII Спартакиадасын ачкан көнне нәкъ шуны расладылар да. Спартакиада элеккеге матур гадәт буенча бу юлы да кунакчыл Нурлат җирендә старт алды.**



ТЕННИСЧЫЛАРНЫ ИЛГИЗ САЛИХОВ СӘЛАМЛИ

Иртән-иртүк "Нурлатнефть" НГДУсының М.Хуҗин исемендәге спорт комплексында спортчылар старт алдыннан җыелына торды. Теннис – спартакиаданың беренче төре, һәм анда "Татнефть" производство төркеме предприятиеләреннән җыелган һәр 37 команданың да үз осталыкларын тулысынча күрсәтәсе килде.

Спартакиаданы ачу тантанасында "Нурлатнефть" НГДУсы начальнигы, ТР Дәүләт Советы депутаты Илгиз Салихов, "Татнефть" ААҖнең профком рәисе Гомәр Яруллин, ярышларның баш хөкемдары Сергей Захаров, "Татнефть" ААҖнең спорт буенча кураторы Дамир Гәрәйшин, "Әлмәтнефть" НГДУсы спорт-сәламәтләндерү үзәгенең сектор мөдире Людмила Җиһаншина һәм башка мәртәбәле кунаклар катнашты.

Гомәр Яруллин үзенең чыгышында: "Илебездә икътисади хәлләр тотрыксыз булса да, спартакиада узды традициясе сакланырга тиеш, чөнки хезмәткәрләрнең сәламәтлеге компания өчен өстенлекле юнәлеш", – диде. Ул активлыклары һәм максатчанлыклары өчен спортчыларга рәхмәт әйтте, шулай ук чараны югары дәрәҗәдә оештырган өчен "Нурлатнефть" НГДУсына да рәхмәтләрен җиткерде.

Нурлат балалар сәнгать мәктәбенең "Дети солнца" хореографик коллективының матур чыгышыннан соң, ярышларның баш хөкемдары уеннарның тәртибе һәм кагыйдәләре белән таныштырды. Алар исә элеккечә үк иде: теннисчыларны өч төркемгә бүлделәр, һәр командада өчәр катнашучы – ике ир-ат һәм бер хатын-кыз.

Теннис кортындагы унике өстәлдә чын спорт алышлары башланды. Соңгы еллар эчендә күп кенә спортчыларның осталыклары да ярыйсы ук шомарган, командаларда яңа исемнәр дә пәйда булган. Һәр катнашучының үз нәтиҗәсен яхшырту гына түгел, ә командага да матур очкылар китерәсе килүе сизелеп тора иде.



НИКОЛАЙ КИРГИЗОВ

Ярышларның нәтиҗәләре буенча, беренче иң зур төркемдә "Әлмәтнефть" НГДУсы җиңүче булды. Икенче урынны "Ямашнефть", IIIне "Лениногорскнефть" НГДУлары алды. Идарәче сервис компанияләре арасында I урын "ТМС групп" ИК ОООсында, "ТАНЕКО" ОООсы һәм "Татспецтранспорт" ИК ОООсы II-III урыннарны бүлештеләр. Өченче төркемдә чемпион исемен яңа "Татнефть-АЗС Центр" ОООсы яулады. Икенче урында узган елгы кебек үк "ТатНИПИнефть", IIIдә "Түбән Кама ТЭЦы" командалары.

"Нурлатнефть" НГДУсы беренче, иң көчле төркемдә чыгыш ясады, идарә данын Николай Киргизов, Андрей Королев һәм Ризидә Ибраһимова якладылар. Быел Нурлат спортчыларына бәхет елмаймады, һәм команда бары тик 9нчы урынны гына алды, әмма, шуңа да карамастан, спортчыларыбыз бик матур уен күрсәттеләр.

Өстәл теннисы ярышлары тәмам. Нефтьчеләрне алда яңа спорт сынаулары көтә. "Татнефть" Спартакиадасының инде моңа кадәр булган тугыз спорт төренә быел тагы ике яңа бәйге – зур теннис һәм бадминтон да өстәлде. Димәк, һәр команданың да үз нәтиҗәләрен яхшыртырга һәм җиңүләр яуларга өстәмә шанслары булачак, дигән сүз.

**Марина КОРНИЛОВА,**
"Нурлатнефть" НГДУсы
Автор фотолары

ЮЛЛАРДА

## Кагыйдәләр кырыслана, тәртипсезләр кимеми

**Яңа ел башланганнан бирле район юлларында 70тән артык юл-транспорт һәлакәте теркәлгән.**

Аларның төп сәбәбе – исерек көе руль артына утыру, каршы як полосага чыгу һәм тизлек режимын арттыру, дип атыйлар ЮХИДИ хезмәткәрләре.

– Юл кагыйдәләренә кертелгән яңа үзгәрешләр нигезендә, хәзер җәяүлеләр кичүләрендә тизлекне арттырып, каршы як полосага чыгу тыела, – ди ЮХИДИнең пропаганда инспекторы Ринат Мөгайнетдинов. – Кагыйдә бозуның беренче очрагында 5000 сум күләмендә административ штраф каралса, кабаттан бозган очракта 4–6 айга машина йөртүче документыннан "колак кагарга" мөмкин. Яңа законнар нигезендә, документы кайтару өчен яңабаштан имтихан тапшырырга кирәклеген дә онытмасыннар иде.

## Төнлә "ялтырап" йөриячәкбез

**Агымдагы елның 1 июленнән гамәлгә керәчәк яңа кагыйдәләр нигезендә, төнлекнең караңгы вакытында җәяүлеләр мәҗбүри рәвештә яктылык кайтаручы элементлы киемнәр киярг тиеш.**

Бу соңгы араларда җәяүлеләр катнашындагы аварияләр санының артуына бәйле, диләр. Мисал өчен, узган ел Нурлат районы юлларында 3 җәяүле машина астында калды.

Юл хәрәкәте кагыйдәләрендәге яңалыклар уңаеннан бу көннәрдә район мәктәпләрендә ЮХИДИ хезмәткәрләре катнашында җыелышлар уза.

**Зилия ӘКСАНОВА**

УҢЫШ



РӘМИСКӘ БҮЛӘКНЕ ЮХИДИ ИНСПЕКТОРЫ ТАПШЫРДЫ

Автор фотосы

## Иминлек мәктәптән башлана

**Фома урта мәктәбенең 9нчы сыйныф укучысы Рәмис Фәхретдинов "Радуги безопасности" Бөтенроссия конкурсының "Имин ракурс" дип аталган номинациясендә III призлы урынны яулаган.**

– Конкурска җәмәгать транспортына багышланган тәкъдир итү эше җибәргән идем, - ди укучы. – Күңелем белән техникага тартылам. Киләсе елдан "В" категорияле машина йөртүчеләр курсына укырга керергә планлаштырам. Ә әлеге уңышымны портфолиома туплап куйдым. Алга таба мәктәпне тәмамлап уку йортына кергәндә өстенлек бирми калмас дип уйлым.

Мәктәпнең 11 сыйныф укучысы Фәзил Гомәров конкурска инша юллап грамота белән бүләкләнсә, Энҗе Хуҗәхмәтова рәсем номинациясендә катнашкан булган.

Призер егет – Рәмис Фәхретдинова алга таба да уңышлар теләп, ТР ЮХИДИ бүлеге әзерләгән электрон китапны ЮХИДИ инспекторы Ринат Мөгайнетдинов тапшырды.

**Зилия ӘКСАНОВА**

КЫСКАЧА

## ЛАБОРАТОРИЯДӘ – КАПИТАЛЬ РЕМОНТ

**Ел башыннан шәһәрнең Гыйматдинов урамында урнашкан ветеринария лабораториясендә капиталь ремонтка керештеләр.**

Төзекләндерү республика ветеринария берләшмәләрен капиталь ремонтлау программасы буенча ясала.

Районның ветеринария берләшмәсе начальнигы Василий Лысов әйтүенчә, ремонтка республика бюджетыннан 2 млн. сум средство бүлеп бирелгән. Бүгенге көндә лабораториянең түбәсе ике яклы итеп корыла, бина сайдинг белән тышланачак, тәрәзәләре алмаштырылачак. 1971нче елда төзелеп, бер тапкыр да капиталь ремонт күрмәгән лабораторияне республика программасына кертү мәсьәләсен район башлыгы Равил Кузюров узган җәйдә күтәргән иде.

**Лилия МӨБАРӘКШИНА**

## ГАИЛӘ БӘЙРӘМЕ ҮТТЕ

Шәһәрнең 9нчы урта мәктәбендә башлангыч сыйныф укытучыларының район семинары кысаларында узган "Әти, әни һәм мин" спорт бәйрәмендә районнан барлыгы 10 гаилә катнашты. Алар балалары 3нче сыйныфта укучы гаиләләр иде. Спорт бәйрәмендә өч эстафетаны да уңышлы үткән Тихоновлар (9нчы мәктәп) һәм Иштуллиннар (Якушкино) гаиләләре җиңү яулады. Аларга район мәгариф идарәсенең Рәхмәт хатлары һәм бүләкләр тапшырылды.

**Зилия ӘКСАНОВА**

27 ГЫЙНВАР – ЛЕНИНГРАД КАМАЛЫШЫН ТУЛЫСЫНЧА ӨЗГӘН КӨН

# Ул гап-гади солдат булган

**Әлеге истәлекле көн алдыннан безнең Илюткинода яшәүче газета укучыбыз Дмитрий Ефремов әтисенең хатирәләре белән уртаклашты, ул аларны 1988нче елда язып алган булган.**

Гаилә архивында Бөек Ватан сугышында катнашкан Иван Ефремовның сугышчан юлын чагылдырган бай мәгълүмати һәм документаль материал тупланган. Әлеге хроникада Ленинград шәһәре аерым урын алып тора, ул анда 1941нче елның сентябрендә, камалышның беренче айларында барып эләгә. Ул чагында берәү дә камалышның 900 көн һәм төн сузыласын күз алдына да китермәгәндер, мөгаен.

Иван Ефремовка машина йөртү таныклыгы булуының сугышта әллә ничә тапкырлар кирәге чыга. Сугышка алынуга Мәскәүгә эләгә, шунда ук аны "ГАЗ-АА" автомобиле руле артына утырталар, аның белән ул ничәмә-ничә чакрымнар фронт юлларын урый. Ә Ленинградка үзенә ышандырылган машинасы белән бөтенләй дә корабльдә килеп төшә. Һәм икенче көнне үк полкташлары белән шәһәрне саклауга кушыла.

"Ижора" заводыннан ерак түгел танк чокырлары иде. Берсендә – без, икенчесендә – якынча 100 метрларда – немецлар. Шулай итеп, көз азагына кадәр атыштык. Декабрьдә безне Троицк кырындагы яңа формированиегә алдылар. Аннан янә шул ук зонаны саклауда майга кадәр булдык. Минем эш ашамлыклар, хәрби һәм башка кирәк-яраклар ташу иде. Шәхси кораллардан винтовкам, револьверым бар иде", - дип сөйли Иван Ефремов сугыштан соң үзенең улына.

1941–42 елларның көзе һәм кышы – камалышның иң коточкыч чоры. Кышның беренче айларыннан ук суыклар башлана – җылылык, кайнар су булмый. Дистрофия һәм суыктан кешеләр меңәрләп үләләр. Иван Ефремовка да ачлыктан хәлсезләнгәннәр өчен стационарда "көчәйтелгән тукландыру"да 18 көн ятып чыгарга туры килә. Бу чорда аның машинасын Ладога аша икмәк ташырга җибәрәләр. Дәвалангannan соң Иван Иванович бернича көн рацияле машина шоферы булып частьның тылында хезмәт итә, ә аннан яңадан формалаштырылган автобатальонга җибәрелә.

Шофер гына түгел, штаттан тыш "писарь" булып та хезмәт итәргә туры килә безнең якташыбызга. Иван Ефремовның матур язуы командир ярдәмчесенең күңеленә аеруча хуш килә. Белеме 5 класс кына булса да, ул ягулык, техниканың төзеклеге һәм башка нәрсәләр турында кәгазьләр, транспорт документлары тутыра, кайчагында диспетчер хезмәтләрен дә үти. Аның карамагында 18 машина һәм шулкадәр үк шофер була. Иван Ефремов камалыш, үзе катнашкан хәрби хәрәкәтләр турында йөрәк әрнүе белән исенә төшерә торган була. Ленинград камалышын өзгәннән соң, Эстония, Варшаваны алуда катнаша. Инде апрель азагына Берлинга килеп җитәләр. Ә анда Иван Иванович хезмәт иткән 220нче танк бригадасы камалышка эләгә. Җиңүгә санаулы көннәр калганда һәлак булган полкташлары өчен никадәр әрнү кичерәләр ул чагында. Алар арасында бригададагы бердәнбер танкчы кыз да була. "Сугышлар 2нче майга кадәр генә дәвам итте. 3нче майда инде Рейхстагны карарга бардык", - дип тәмамлана ветеран улының шәхси язмалары. Ел саен 27 гыйнвар - Хәрби дан көнендә Дмитрий Ефремов шәхси архивын барлый, әтисенең истәлекләрен, күз карашын, елмаюын, йөз чалымнарын хәтерендә яңарта. Аның фикеренчә, Җиңүнең 70 еллыгы алдыннан әтисе сыман Бөек Ватан сугышында катнашкан гап-гади солдатларның күзгә күренмәс батырлыклары турында сөйләү бик кирәк.

**Маргарита ЛИТТА**

ГАББАС ГЫЙМАТДИНОВ ИСТӘЛЕГЕНӘ

# "Без – Гыйматдинов мәктәбен узган буын"

**Рәшит Гыймалетдинов, хезмәт ветераны, Нурлат шәһәренең мактаулы гражданы, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены кавалеры:**

*- Габбас Кыямович белән якыннан беренче аралашуым моннан нәкъ 50 ел элек булды. Ул чагында мине "Комбайн" колхозының 1нче комплексына бригадир итеп билгеләгәннәр иде. Габбас Гыйматдинов бригадада эшләрнең барышы белән танышып чыкты. Миңа калса, канәгать калды, тегеяки бу юнәлеш буенча киңәшләр дә бирде. Ә соңыннан кереп 25 елдан артыграк "Комбайн" колхозын җитәкләп, лаеклы ялга чыккан әтием Һади Гыймалетдиновичның хәлләрен белешеп чыгарга да вакыт тапты. Шактый гына гәпләшеп утырдылар, дөнья хәлләре, район тормышы турында сөйләштеләр. Хәзер шактый еллар узгач, бу очрашуны исемә төшерәм дә, уйлап куям: Габбас Кыямович инде ул вакытта үзе дә тәҗрибәле җитәкче, райком секретареның вакыт ягы да кысан булгандыр, шулай да өлкән кеше белән аралашып, киңәш-табыш итүне кирәк дип санаган һәм җаен да тапкан. Бу исә минем өчен яхшы сабак булды: һәр эштә өлкән буынның тәҗрибәсенә таянып, фикерләрен тыңлап эшләү кирәк.*

*Габбас Кыямович өлкәннәргә ихтирамлы, яшьләргә карата таләпчән иде. Һәрвакыт төгәл, грамоталы һәм гадел җитәкче кул астындагылардан да шуны таләп итә белде. Мин исә 1969нчы елда "XXI партсъезд ис." колхозга рәис итеп билгеләндем. Аның кул астында 18 ел эшләдем һәм бу елларда "Габбас Гыйматдинов мәктәбе"н уздым дип әйтә алам. Һәм бер минем өчен генә түгел, безнең буынга һәр сүзе, һәр гамәле белән үрнәк, ихтирамлы остаз булды ул.*

# Фоторәсемдә сакланган тарихи мизгел

**Әнвәр Насыйбуллин, хезмәт ветераны, Чулпан авылы:**

*- Габбас Гыйматдинов эшләгән еллар – районда зур төзелешләр, матур үзгәрешләр барган чор. Бу вакытта безнең якларда да тормыш кайнап торды. 80нче еллар азагында Чулпан һәм Заречный авыллары арасында күпер төзелү дә безнең яклар, аеруча шул як авыллар өчен тарихи вакыйга булды, чөнки бу күпер ул чагында иң әһәмиятле объектларның берсе иде бит. Аның ачылу тантанасына исә КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Гомәр Усманов һәм райкомның беренче секретаре Габбас Гыйматдинов килде. Мин ул вакытта шофер булып эшлим, тасма кискән вакытка бераз өлгерми калдым, әмма фотоаппаратым гадәттәгечә янымда һәм ерактан булса да дәрәҗәле кунакларны халык арасында фоторәсемгә төшерергә өлгердем. Кызганыч, анда Габбас Кыямовичның йөзе күренми, әмма җитәкчеләр белән халыкның бик матур аралашу мизгеле тарихка кереп калган. Еллар үтү белән саргаерга өлгергән әлеге фоторәсемне хәзер дә матур истәлек итеп саклыйм.*

**Лилия МӨБАРӘКШИНА** язып алды

ШӨГЫЛЬ



Автор фотосы

ВАКЫТЛАРЫ БУЛДЫМЫ – БАЛЫКЧЫЛАР БУАГА АШЫГА

# Боз астында балык бар

**Калын боз белән капланган Иске Чаллы авылы буасында еш кына кышын балык тотарга яратучыларны күрергә була. Бирегә алар 15ләп кеше җыелалар.**

– Биредә рәхәтләнеп ял итәсең, - ди кармагыннан күзен алмый гына Николай Нилов.

– Һөнәрмән үз эшен белә, - дип сүзгә кушылалар аның әлеге шөгыль буенча коллегалары. – Ул безнең арада иң хирыс балыкчы!

Аның оста булуын тотылган балыклары да раслый. Николайның бәкесе тирәсендәге алабугалар башкаларныкына караганда күбрәк. "Балык шулпага да, кыздырырга да җитә", – дип елмая балыкчы һәм шунда ук табышын уртаклашырга да тәкъдим итә.

Менә 15 еллар инде авылдашы Владимир Красников белән алар сезон башыннан ук буага йөриләр. Алар артыннан башка балыкчылар да тартыла. Биредә еш кына нурлатлыларны да очратырга мөмкин. Балыкчыларның яраткан урыннары да бар. Иске чаллылар башка сулыкларга да йөриләр, Камага баручылары да бар. Шулай да күңелләре белән туган җирләренә тартылганнар.

– Куркыныч түгелме? Боз бит. Кайчан, кайдан чатнавын да белмисең, –дип сорыйм

– Курыкмагыз, - диләр минем сагаюны күргән балыкчылар. – Хәзер бозның калынлыгы ярты метрдан артыграк. Беренче бозга, әле аның калынлыгы 6-8 сантиметр булганда чыккан вакытлар да бар иде.

– Нәрсәгә тотасыз? – дип сораштырам (кышын суалчан казып булмый бит инде).

– Озынборын личинкасына, – дип елмая Николай Рассадин, минем уйларымны укыгандай.

Балык тотучыларның күбесе серләрен ачарга яратмый. Шуңа да аларны башка борчымадым.

– Һәркайсыбызның үз рекорды бар, - дип уртаклаша Николай Нилов. – Балыкчылык – күңел халәте бит ул. Күпме тотуың мөһим түгел, рәхәтләнеп ял итәсең.

Балыкчылар белән аз гына аралашсаң да, аларның күңел халәтен аңлый башлыйсың сыман. Кышкы табигатьнең үз матурлыгы шул. Ә саф һава сәламәтлек өчен файдалы. Ярты көн дәвамында салкында боз өстендә утыру бар кешенең дә күңеленә ятып бетми, билгеле. Шуңа күрә дә моның өчен чын балыкчы булырга кирәктер.

**Маргарита ЛИТТА**

КЕШЕ ҺӘМ ЗАКОН

# Комарлы уен яхшыга илтми

**Бер карашка, әлләни куркыныч булмаган әлеге шөгыль "уенга бәйлелек" исемле чиргә әверелергә мөмкин, моның исә шәхес буларак юкка чыгуга, гаиләнең таркалуына һәм җинаятьләр артуга китерүе ихтимал.**

Бу проблема безнең шәһәрне дә читләтеп үтмәде, Нурлатта законда тыелган уен биналары бернича тапкырлар ачыкланганы бар. Шундый уен салоннарының берсе Гыйматдинов ур., 84нче йортның подвалында тулы конспирация шартларында урнашкан иде. Уен салонын оештыручылар криминаль жанрның иң шәп романнары йогынтысында тәрбияләнгәннәр, күрәсең. Өстәвенә, бу закон бозучылар чиктән тыш оятсыз да булып чыкты әле. Полиция хезмәткәрләренә уен җиһазларына өч тапкыр арест салырга һәм салонны өч тапкыр ябарга туры килде. Мондый эшчәнлекне туктату турындагы кисәтүдән соң, хокук бозучылар яңа җиһазлар кайтарталар, ә салон эшен дәвам итә. Беркатлы нурлатлылардан кергән җиңел табыш уен оештыручыларда җәзасыз калуда ышаныч тудыра, ахрысы. Җәмгыятьтә тыелган мондый хәл гамәлдәге законның бик үк камил булмавы белән дә бәйле, әлбәттә. Ниһаять, РФның 2014 елның 22 декабрендәге №403-ФЗ Федераль законы белән әлеге җитешсезлек бетерелде. 2015 елның 3 гыйнвареннан РФ Җинаять Кодексына үзгәрешләр үз көченә керде. РФ ҖКның 171.2 маддәсе нигезендә, комарлы уенны үткәрүчене дә (ягъни оператор), мондый уеннарны оештыручыны да җинаять җаваплылыгына тарту мөмкинлеге каралган, һәм биредә әлеге затларга кергән табышның күләме бернинди роль уйнамый. Әлеге маддә буенча максималь җәза өч елга ирекtән мәхрүм итүне күздә тота.

Бу закон хокук саклау һәм прокуратура органнарына җәмгыятьтәге әлеге чирнең тамырына балта чабарга ярдәм итәчәк.

**Рамил ГАРИФУЛЛИН,**
Нурлат шәһәре прокуроры

**NURLAT-TAT.RU САЙТЫНДА БАШКА КҮП ТӨРЛЕ ЯҢАЛЫКЛАР ТУРЫНДА БЕЛӘ АЛАСЫЗ**

# ТӨРЛЕ. БЕЛДЕРҮЛӘР

ШӘФКАТЬЛЕЛЕК




КАМИЛЛАГА БҮЛӘКНЕ МӘКТӘПКӘ КИТЕРЕП ТАПШЫРДЫЛАР

## Камилланың тимераягы бар

**Шәһәрнең 9нчы урта мәктәбе укучысы Камилла Абрамованың хыялы тормышка ашты. Ул Кыш Бабай бүләге – фигуралы шуу өчен тимераякка ия булды.**

– Яңа ел бүләге турында күптәннән хыяллана идем, - ди мәктәпнең 2Б сыйныфы укучысы Камилла. – Тимераякка басып карыйсым, яшьтәшләрем кебек үк түгәрәккә йөрисем килде. Яңа ел алдыннан әнием белән бергәләп Кыш Бабайга хат юлладык.

Кызның теләген Кыш Бабайның "ярдәмчесе" – район башлыгы Равил Кузюров тормышка ашырды. Тулы булмаган гаиләдә тәрбияләнүче Камиллага ул бүләк кенә ясап калмады, ә "Ледок" Боз сараенда тимераякта шуып карау мөмкинлеге дә тудырды. Бүләкләрне Камиллага район мәгариф идарәсе начальнигы Линар Маняпов һәм "Ледок" Боз сарае директоры Марсель Садыйков тапшырдылар.

**Зилия ӘКСАНОВА**

"ТАТНЕФТЬ" ААҖндә

## Управление по реализации проектов строительства ОАО "Татнефть" подвело итоги 2014 года

**Подведены итоги выполнения производственных планов и коллективного договора за 2014 год трудового коллектива Управления по реализации проектов строительства (УРПС) ОАО "Татнефть".**

В прошедшем году УРПС курировал проекты, связанные с продолжением строительства Комплекса "ТАНЕКО", реконструкцией ООО "Нижнекамская ТЭЦ" и разработкой залежей Ашальчинского месторождения сверхвязкой нефти. В ходе их реализации было освоено 20,4 млрд рублей.

Коллектив управления обеспечил высокую степень строительной готовности комбинированной установки гидрокрекинга и выполнил запланированный объём пусконаладочных работ, что позволило начать выпуск экологически чистого дизельного топлива стандарта "Евро-5", авиационного керосина марок ТС - 1, РТ, Джет А -1 и базовых масел II и III групп. Также велись проектные и строительно-монтажные работы на установках гидроочисток дизельного топлива, керосина, нафты; установке замедленного коксования; комплексе производства ароматики и объектах общезаводского хозяйства, обеспечивающих их работоспособность.

В течение 2014 года УРПС вышло на новый уровень в реконструкции Нижнекамской ТЭЦ: завершаются работы по расширению главного корпуса, строительству циркуляционной насосной станции, двух башенных и двух вентиляторных градирен. Начало комплексного опробования на данном объекте планируется с наступлением более благоприятного температурного режима. Ввод в эксплуатацию двух турбин позволит добавить к установленной мощности ТЭЦ 350 МВт и увеличить ее до 730 МВт.

Главные задачи, поставленные перед коллективом УРПС на 2015 год - реализовывать уже начатые проекты, завершить строительно-монтажные работы и приступить к пусконаладке на установке замедленного коксования, среди приоритетов - продолжение реконструкции ТЭЦ и освоение Ашальчинского месторождения сверхвязкой нефти.

На собрании было отмечено, что социальные обязательства в рамках коллективного договора, в отчетный период успешно выполнены.

*На правах рекламы*


## КҮЧЕМСЕЗ МИЛЕК

*Ленин ур., 45тә бүлмә. Т. 8-937-524-94-36.

*Йорт. Т. 8-919-684-40-03.

*Үзәктә фатир, 30 кв.м, 1нче кат. Т. 8-927-031-23-45.

*2 бүлмәле фатир. Т. 8-927-493-21-89.

*Үзәктә 2 бүлмәле фатир. Т. 8-927-418-86-92.

*Биляр-Озерода йорт. Т. 8-927-425-10-16.

*Төрнәстә 2 бүлмәле фатир. Т. 8-927-405-45-03.

*Малосемейка, Яшьлек мкр., зур як. Бәясен килешербез. Дружба ур., 76-22гә мөрәҗәгать итәргә. Т.: 8-927-485-20-36, 8-937-288-64-11.

*1 бүлмәле фатир, Мәктәп ур., 29, 46 кв.м. Т. 8-927-243-65-08.

*Йорт, Кутузов ур. Т. 8-927-243-65-08.

*Йорт, Тимерҗанов ур. Т. 8-927-442-65-26.

*Яңа торак йорт, 100 кв.м, 1850000 сум. Т. 8-937-610-48-70.

*Торак йорт, 120 кв.м, 2,5 млн. сум. Т. 8-937-610-48-70.

*Киекледә торак йорт, 700000 сум. Т. 8-937-610-48-70.

*Салдакайда торак йорт, 400000 сум. Т. 8-937-610-48-70.

*Түбән Чаллыда торак йорт, 850000 сум. Т. 8-937-610-48-70.

*Егоркинода торак йорт, 600000 сум. Т. 8-937-610-48-70.

*Яңа коттедж, 4 млн. сум. Т. 8-937-610-48-70.

*Үзәктә коттедж, 4,5 млн. сум. Т. 8-937-610-48-70.

*Элиталы коттедж, 6,7 млн. сум. Т. 8-937-610-48-70.

*2 бүлмәле фатир, үзәк, 950000 сум. Т. 8-937-610-48-70.

*2 бүлмәле фатир, ш/з, 850000 сум. Т. 8-937-610-48-70.

*3 бүлмәле фатир, мансард, 850000 сум. Т. 8-937-610-48-70.

*1 бүлмәле яңа фатир, 2нче кат, 1 млн. сум, 40 кв.м. Т. 8-937-610-48-70.

*Т/ю.да торак йорт, 48 кв.м, 650000 сум. Т. 8-937-610-48-70.

*Т/ю.да торак йорт, 320000 сум. Т. 8-937-610-48-70.

*Нигез салынган участок (Түбән Нурлат). Т. 8-927-415-01-51. №16-16-35/017/2011-525 м/х.

*«Золотая подкова» кафесы. Т. 8-927-030-95-31.

*1 бүлмәле фатир, 38 кв.м. Т. 8-937-293-28-71.

*Ашыгыч, Завод ур.да 1 бүлмәле фатир, балкон, пластик тәрәзәләр, төп коммуникацияләр – җылылык һәм канализация торбалары алыштырылган. Асфальтланган ишегалды, йорт сайдинг белән тышланган, фатир 2 катлы йортның 1нче катында. Т. 8-960-056-55-66.

*2 бүлмәле фатир, Ключи пос.. Т. 8-937-613-06-08.

*Җир участогы (корылмалар юк), Алга ур. (Кормыш пос.), ут, газ, су үткәрелгән. Юлга асфальт салынган. Т. 8-927-671-15-60. 1600/301/14-620462 м/х.

## АВТОТРАНСПОРТ

*«ГАЗель», 7 урынлы, тоташ тимердән, 2011 елгы, бик яхшы, 90000 км йөргән, бәясен килешербез. Т. 8-937-776-59-18.

*«Джилли МК», 2010 елгы, 25000 км йөргән. Бәясен килешербез. Т. 8-917-886-57-85.

*«Ока», 2005 елгы, 30000 сум. Т. 8-917-938-62-58.

*«Калина», седан, 2006 елгы. Т. 8-927-401-97-48.

*«Шевроле Нива», 2008 елгы, яхшы, кара. Т. 8-937-281-00-27.

*«КИА Спектра», 2008 елгы. Т. 8-927-48-000-74.

*«Лада Калина», седан, 2010 елгы. Т. 8-937-524-88-48.

*«Renault Duster», 2013 елгы, ачык соры. Бәясен килешербез. Т. 8-927-400-72-91.

*«ВАЗ-2114», 2013 елгы, люкс. Т. 8-917-259-33-23.

*«Лада Гранта», 2014 елгы. Т. 8-927-038-12-40.

## БАШКАЛАР

*Удмуртиядән теләсә нинди катлаулылыктагы буралар, идән, түшәм, бәпкәләр белән комплектланганнары һәм комплектсызлары да бар; төрле үлчәмнәрдәге өйләр һәм мунчалар. Т. 8-987-008-60-31.

*Төргәктә био-туалет, арзан. Т. 2-87-04.

*ПГС, ком, елга ташы, жом. Т.: 8-927-402-13-40.

*Су скважиналары бораулау өчен җайланма. Т. 8-937-285-19-00.

*Бәрәңге. Т. 8-937-775-97-34.*Үгез бозаулар, китерәбез. Т. 8-927-870-49-62.

*Какланган казлар һәм түшкәләр. Т.: 8-937-588-27-15, 8-960-033-23-77.

*Бәрәннәре белән сарыклар (60 баш). Т. 8-937-777-27-01.

*Кәрәз (Ульяннныкы), 400 сум/кг. Т. 8-927-751-61-46.

*Стенка (Польша), 8000 сум. Сатулашу. Т. 8-927-670-38-21.

*Стенка, 5000 сум. Сатулашу. Т. 8-937-004-93-06.

*Эре терлек ите. Т. 8-927-448-32-25.

*Бодай, арпа. Китерү – түләүсез. Т. 8-937-776-33-35.

*11 айлык тана. Т. 8-927-419-89-28.

*Бодай, арпа, солы, болын печәне. Китерәбез Т.: 8-927-470-08-25, 2-69-45.

*Балалар диваны, кулланылган. Т. 8-937-00-66-751.

***Жалюзи, барлык төрләр. Тиз. Т. 8-927-672-01-17.**

*Йомшак җиһаз. Т.: 2-45-47, 8-927-491-97-80.

*Кәрәз (Ульяннныкы), 420 сум/кг. Т. 8-927-751-61-46.

*Просечкадан коймалар, чардуганнар. Т. 8-917-863-93-44.

*Утын. Т. 8-987-413-91-33.

## ТӨРЛЕСЕННӘН

***Йөк күчерү, «ГАЗель». Т. 8-937-570-60-21.**

***Йомшак җиһаз тарттыру, ремонтлау. Т. 8-937-570-60-21.**

*Такси: Нурлат-Самара. Көн саен. Өегездән килеп алам. Т. 8-927-673-79-46.

*Электр монтажлау эшләре. Т. 8-937-614-70-15.

*Юрист хезмәтләре. Т. 8-927-415-01-51.

*Сантехника (су, канализация, җылылык үткәрү). Т. 8-927-413-17-69.

*Юрист хезмәтләре: ДТПның иминият түләвен алу. Т. 8-927-415-01-51.

*Йөк күчерү. Т. 8-929-721-37-65.

*Кер юу машиналары һәм су җылыткычлар төзәтәм. Т.: 8-927-468-16-31, 8-917-926-34-78.

*«ГородСтрой» ОООсы заказчының үз проекты буенча шәхси торак йортлар төзүгә заказлар кабул итә. Т.: 2-85-45, 2-85-22, 8-927-423-72-22.

*«Рено» документларын табучының аларны кайтарып бирүен сорыйм. Буш итмәм. Т. 8-937-616-47-27.

*Өегезгә килеп суыткычлар төзәтәм. Т. 8-927-419-56-48.

*Суыткычлар төзәтәм. Т.: 2-71-69, 8-937-610-58-78.

*Суыткычлар төзәтәм. Т. 8-927-247-93-50.

*Компьютерыгызга ярдәм. Т. 8-909-308-22-56.

*Кар көрибез. Т. 8-927-244-84-71.

*Йөк күчерү. Т. 8-927-401-11-76.

*Программалаучы эше эзлим. Т. 8-927-425-05-75.

*Электрик хезмәтләре. Т. 8-987-418-35-00.

*Мәче бирәм. Т. 8-937-527-41-90.

***Фатирлар ремонтлау (барлык төр эшләр), ахыргача җиткереп, юыну бүлмәләренә ремонт ясау. Т. 8-927-484-47-33.**

*Бәхетле туйлар, күңелле юбилейлар. Алып баручылар. 8-950-321-17-29.

*«ГАЗель», йөк күчерү. Т. 8-927-486-10-22.

*Тигезләү, обойлар ябыштыру. Т. 8-929-722-40-32.

*Коелар казыйбыз, чистартабыз. Т. 8-927-481-51-72.

*Пластик тәрәзәләр ремонтлау. Т. 8-927-249-54-24.

*Йөк күчерү, «ГАЗель», 4,20 тент. Т. 8-927-442-38-10.

*Сантехника (су, канализация, җылылык). Т. 8-937-526-56-86.

*ПГС, ком, «МТЗ» төягече белән кар чистарту. Т. 8-927-424-02-83.

## САТЫП АЛАМ

***Алгы приводлы «ВАЗ»лар, чит ил машиналары. Кыйммәткә. Т. 8-927-456-00-07.**

*Мөгезле эре терлек тиреләре, кыйммәткә. Т. 8-937-281-75-63.

*Мөгезле эре терлек, кыйммәткә. Т. 8-927-412-29-99.

*Авылдан документлары булган йорт, кыйммәткә түгел. Т. 8-937-583-21-80.

## КИРӘК

*Казанда фатир. Т. 8-937-525-20-02.

*Оешмага даими эшкә ПОС монтажлау һәм хезмәт күрсәтү буенча белгечләр. Т.: 2-92-03, 8-919-636-70-17.

*Гаиләгә фатир. Т. 8-937-775-49-00.

*«Теремок» кибетенә сатучы, оклад 12000 сум. Т. 8-937-777-00-08.

*«Перспектива» ОООсына «КамАЗ»га шофер, кранчы, экскаваторчы, эретеп ябыштыручы (тәҗрибә). Эш режимы 8.00дән 17.00гә кадәр, 2 ял көне (тору урыны бирелә). Элемтә өчен тел.: 2-58-21, 2-58-24. Адрес: Нурлат, Завод ур., 1.

*Чәчтараш, маникюр ясаучы. Т. 8-927-421-80-33.

*«Нурлат УТТсы» ОООсына эшкә: 1) күтәрткеч машинистлары; 2) цементацияләү агрегатлары мотористлары; 3) пар белән эшли торган күчмә депарафинизация җайланмалары машинистлары; 4) автовышка һәм автогидрокүтәрткеч машинистлары; 5) күчмә компрессор машинистлары; 6) ВСЕ категорияле (+ Допог – куркыныч йөкләр ташуга рөхсәт бирүче таныклык) шоферлар. Т. 90-154.

*«Промочистка» ОООсына С категорияле шофер, тракторчы. Т. 2-03-29.

*«ТМНУ» ААҖнә даими эшкә инженер-сметалаучы, КИПиА слесарьлары. Т. 8-917-238-04-91.

*«Услуга» ОООсына медицина белеменә ия массаж ясаучы. Т.: 2-43-04, 2-43-03.

*Нурлат РЭСына электромонтер, куркынычсызлык буенча 3нче группа. Т.: 2-38-77, 8-917-398-26-41.

*«УК ЖКХ» МУПына участок мастеры (юл эшләрен белү). Хезмәт хакы яхшы. Т. 2-05-50.

## БИРЕП ТОРЫЛА

*Үзәктән тәүлекләп фатир, чеклар. Т. 8-929-727-47-80.

*Тәүлекләп фатир. Т. 8-927-406-11-06.

*Тәүлекләп 1, 2 бүлмәле фатирлар. Т. 8-927-456-59-10.

*Тәүлекләп фатир. Т. 8-927-448-33-48.

*Шәһәр үзәгендә бина, 80 кв.м, ярдәмче биналары бар. Т. 8-927-672-50-37.

*2 бүлмәле фатир, үзәк. Т. 8-937-597-09-44.

*Үзәктә 2 бүлмәле фатир. Т. 8-987-279-32-00.

*Командировкадагыларга сәгатьләп, тәүлекләп фатир. Т.: 8-927-456-05-69, 8-927-402-35-86.

*Гаиләлеләргә 1 бүлмәле фатир, үзәк. Т. 8-937-293-25-49.

*Массаж ясый торган кабинет. Т. 8-927-406-11-06.

*«Шифа» сәүдә үзәге янында 3 бүлмәле җиһазлы фатир. Т. 8-917-275-16-76.

*Арендага бина (Совет ур., 177дә яңа мунча). Т. 2-05-50.


## ЮГАЛТУЛАР

*Машина брелогы ("сигналка" + ачкычлар) табучының 8-927-037-45-50, 2-24-57 номерларына шалтыратуын сорыйм.

*Нурлат муниципаль районының Яңа Иглай урта гомумбелем бирү мәктәбе тарафыннан 2008 елда Рузил Ришат улы Насыйров исеменә төп гомуми белем турында бирелгән 16ББ серияле №0070931 аттестатны югалу сәбәпле гамәлдән чыккан дип исәпләргә.

*17 гыйнварда 19.00 сәг.тә Боз сараенда 41нче үлчәмле ир-ат ботинкасын (кара, яннан молнияле, алдан шнурлы) 42нче үлчәмлегә алмаштырганнар. Кайтарып бирүегезне сорыйм. Т. 2-92-70.

*Илгиз Ильяс улы Идрисов исеменә машина йөртүче таныклыгын кайтарып бирүегезне сорыйм. Буш итмәм. Т. 8-929-725-22-37.

*Кара брелок-ачкыч югалды. Табучыга – бүләк. Т. 8-937-006-67-91.

## РӘХМӘТЕБЕЗ ЧИКСЕЗ

Әниебез **Хәйрия Гайсә кызы Хисамиеваны** соңгы юлга озатканда күрсәткән ярдәмнәре өчен «НурлатАвтоТранс» ОООсы (шәхсән аның директоры Ә.Х.Гыйматдиновка), «Нурлат УТТсы» ОООсы (шәхсән аның директоры И.А.Галиевка) коллективларына, эксплуатация начальнигы М.В.Емельяновка, күршеләргә (Миңнеруй апага, Гөлшатка), туганнарга, дусларга һәм авыр чакта рухи һәм матди ярдәм күрсәткән һәркемгә олы рәхмәт белдерәбез.

**Балалары, оныклары.**

## Кайгы уртаклашабыз

«Җирлекара үзәк китапханә» МБУсы коллективы,

**әнисе**

вафат булу сәбәпле, Чулпан авыл китапханәсе китапханәчесе Роза Вәгыйзь кызы Хәлимованың һәм аның якыннары, туганнарының тирән кайгысын уртаклаша.

Кычытканлы авылы җирлеге башкарма комитеты, тормыш иптәше

**Мәдинә Шәрифулла кызы Билданованың**

вафат булуы сәбәпле, Кычытканлы авылында озак еллар колхоз рәисе булып эшләгән Замир Шамил улы Билдановның, балаларының, якын туганнарының авыр хәсрәтләрен уртаклаша, кайгылы көннәрендә сабырлык, түземлек тели. Ходай сезгә югалту хәсрәтләрен күтәрерлек көч, чыдамлык бирсен.

***

Тормыш иптәше

**Мәдинә Шәрифулла кызы Билданованың**

вафат булуы сәбәпле, озак еллар Нурлат районының "Татарстан" колхозы рәисе булып эшләгән Замир Шамил улы Билдановның, балаларының, якын туганнарының тирән хәсрәтләрен уртаклашабыз, кайгылы көннәрендә сабырлык, түземлек телибез.

**Авылдашлары һәм хезмәттәшләре Җ.З.Нургалиев, С.М.Мотаһиров.**